| | | |
|---|---|---|
| КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ<br>КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ<br>МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН<br>САКЛАУ КОМИТЕТЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.05.2026 № 281-П

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Большая Красная урамы, 68 йорт адресы буенча урнашкан «1845 – 1846 елларда А.Н.Толстой яшәгән йорт», 1845 – 1846 еллар, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты турында белешмәләрне төгәлләштерү хакында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының 2026 елның 15 апрелендәге уңай бәяләмәсе нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Большая Красная урамы, 68 йорт адресы буенча урнашкан «1845 – 1846 елларда А.Н.Толстой яшәгән йорт», 1845 – 1846 еллар, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты турында белешмәләрне, атамасын «А.Н.Толстой яшәгән йорт» дип үзгәртеп, төгәлләштерергә

2. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә күрсәтелгән мәдәни мирас объектының атамасы турында белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына һәм Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис И.Н.Гущин